СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2023 г. Зеленодольск № 357

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 145 номерлы, 2023 елның 20 июлендәге 298 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы,Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 145 номерлы, 2023 елның 20 июлендәге 298 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.5. пунктындагы икенче абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру эшчәнлеге җитәкчелеген Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе башкара.

1.3. 1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнарының вазифаи затлары исемлеген билгели һәм (яки) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль учреждениеләргә вәкаләтләр бирә.

Муниципаль торак контролен башкару вәкаләтләре бирелгән муниципаль учреждениеләр, үз бурычларына муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кергән, вазыйфаи затларны билгелиләр.

Контроль орган исеменнән муниципаль торак контролен әлеге Нигезләмә, вазыйфаи регламент яки вазыйфаи инструкция нигезендә муниципаль торак контроле төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү вазыйфаи бурычларына керә торган вазыйфаи затлар (алга таба – инспектор) башкара.

Контроль орган җитәкчесе контроль чараны үткәрү турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазифаи зат булып тора (алга таба Контроль органның вәкаләтле вазифаи зат).»

1.4. Нигезләмәгә «Зеленодольск муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге» 1 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

1.5.Нигезләмәнең «Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда контроль чаралар уздыру өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары» 3 нче кушымтасын, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча, түбәндә бирелгән редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Советы Рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1648017831 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2023 елның 28 декабрендәге 357 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы Советының
2021 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы карары белән
расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль
районы җирлекләре территориясендә муниципаль торак
контроле турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары**

1. Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күп фатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.

2.Дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүматның, дәүләт торак күзәтчелеге органыннан, муниципаль торак контроле органы адресына гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән килгән) яки күп фатирлы йортта биналар хуҗасы булган оешмалардан, күп фатирлы йортта биналардан файдаланучы гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр санының, шушы календарь елның бер чоры (ай, квартал) белән чагыштырганда, вакыт берәмлеге (ай, квартал) өчен өч мәртәбә һәм аннан артып китүе.

3. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

4. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылучы зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасын чакыру.

5. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күп фатирлы йорт биналары милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләме , алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда, 50% тан артыграк булуы турында белешмәләрне ачыклау.»